Reviews

Бәяләмә һәм күзәтүләр

Рецензии и обзоры

DOI: 10.26907/2311-2042-2025-24-1-153-162

# A NEW BOOK ABOUT THE KHAN OF THE MUSICAL STATE (REVIEW OF THE POPULAR SCIENCE COLLECTION “ILHAM SHAKIROV”, PUBLISHED BY THE “ZHYEN” FOUNDATION)

**Chulpan Afraimovna Zaripova-Chetin,**
Caucasus University,
36000, Turkey,
chulpancetin@gmail.com.

**Gulsah Yilmaz,**
Afyon Kocatepe University,
Afyonkarahisar, 0300, Turkey,
gulsahyilmaz4048@gmail.com.

The article is a review of a popular science collection about the legendary Tatar singer Ilham Shakirov. We evaluate biographical, literary and popular science materials presented in the book.

**Key words**: Tatar culture, Tatar music, Ilham Shakirov, song traditions, folk song

**For citation:** Zaripova-Chetin, Ch., Yilmaz, G. A new book about the khan of the musical state (review of the popular science collection “Ilham Shakirov”, published by the “Zhyen” foundation) // Tatarica. 2025. № 1 (24). pp. 153–162. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-153-162

In 2024, the “Zhyen” Foundation released the popular science collection “Ilham Shakirov”, dedicated to the great singer Ilham Gilmetdinovich Shakirov [1]. This book includes warm words and valuable reviews written by the singer’s contemporaries – scientists, writers, artists and public figures. This collection, according to its compiler Marcel Galeev, is perceived “as an anthem, a made-from-words monument of an outstanding person who is one in a million” [1].

Several books dedicated to Ilham, who was the origin of the Tatar folk melody of “the past, today and the future” [1, p. 3], were published earlier. Thus, in 1973, the book “The Singer” about Ilham Shakirov was published by Ravil Fakhretdinov [2]. Razil Valeev created a book-album “Ilham” timed to the singer-composer’s 80$^{th}$ anniversary [3]. Five years later, Garay Rahim, with the support of the “Zhyen” Foundation, prepared a new book-album, “Illahi Ilham” (“Divine Ilham”) [4]. Here, readers can find interesting, informative articles about

Ilham Shakirov's life and work, warm memories, as well as numerous photographs.

In 2024, on the occasion of the 90th anniversary of the great singer's birth, the "Zhyen" Foundation released a new collection consisting of four parts [1]. In the preface "Ilhamly khalyknyn ilkhany bulyr", the compiler of the book, Marcel Galeev, shared his memoirs, focusing on the biography of Ilham Shakirov and noted his significant place in Tatar musical art and life: "Ilham was the star that suddenly entered the Tatar song universe in the mid-fifties and had a huge impact on my people, living on the territory stretching from Lake Tatarika in Estonia to the Tatar Strait of the Russian Far East, the one who could inspire, give hope for healing, who could comfort and awaken the spirit" [1, p. 3]. To hear the "mighty magic of the Tatar melody", the writer invites you to go on a fascinating journey, devoted to the life and work of Ilham Shakirov who inspired us with dozens of his songs that found an echo in the soul of his contemporaries. "Segat chylbyry" ("The Chain of the Clock"), "Medinekei", "Kara urman" ("A Thick Forest"), "Uel" ("Carve into"), "Teftileu" gave his listeners the moments of happiness; having talked with elders, he found long-forgotten melodies and letting them pass through his soul, he breathed new life into them and returned them to the people. Reminding the singer of the mission entrusted to him by heaven, the author says: "Wake the lost souls up with your God-given voice! May the memory turn over! Let the fires flare up in place of the extinguished bonfires, plunging into the age-old flame, alarm those who have lost the meaning of life! Sing, let your heart flutter, let your spirit flutter, calm the great Tatar people! You are the master of the dark forest, the master of melody" [1, p. 28]. In the preface to the collection, Marcel Galeev includes his lyrical essay "Galibane mon" ("Galibana Melody"), taken from the book "Rukh" ("The Spirit"). In this essay, he shares with the readers his philosophical ideas about the Tatar melody, which is the golden pillar of Ilham Shakirov's work, and reminds them of the glorious historical path of the Tatar people: "In the Tatar melody there is a sadness of the Turks, similar to the sadness of Sak and Sok who, waving their banners with embroidered golden wolf heads, riding Karabair jurgahs (a breed of Karabair horses), conquered continents and spread to different countries! ... In the Tatar melody, there is a mournful coal whisper of bonfires lit in the steppes of the Golden Horde by the Kipchak musafirs (wanderers) who lost their country after Idegey! ... In the Tatar melody, there is a sinlessly trembling depth of dark forests, raging like the sea from the Volga Elms beyond the malachite Ural ridges to the Siberian larches!" [1, pp. 29, 30]. In agreement with Adler Timergalin's review, we can say that it is a wonderful literary portrait by a master of the pen, who could breathe his soul into his work, which has not been seen so far and cannot be seen these days either: "Marcel Galeev is happy: he is a master of language. Nature has endowed him with absolute mastery, and he has received the keys to language from God. Marcel Galiev uses a lot of examples of grace" [5, pp. 374, 383]. In general, after reading what Marcel Galeev has written about Ilham Shakirov, we feel a desire: "Oh, if only Marcel abyi wrote a novel about our great singer in a masterful and poetic literary language!" Perhaps, this preface is just those pages of the novel that will be written in the near future...

The first chapter of the collection, entitled "Ilhamny sagynyp" ("Missing Ilham"), includes the only work about Ilham Shakirov – "Zhyrchy" (The Singer") by Ravil Fakhretdinov published in 1973. This work, which contains very valuable memories related to Ilham Shakirov and excerpts from letters received from his fans, provides an opportunity to look into the life and creative work of the singer, as well as into the life of the village during the terrible war and post-war years. Ravil Fakhretdinov highly appreciates Ilham Shakirov, his singing and performing skills, his amazing voice and its deep melody. The writer explores "what the singer found in folk music, in what form he returned its gems to the people": "The national glory of our composers' works is the spirit of folk music and folk melodies they are based on. There are undiscovered treasures of folk art and folk genius in folk songs. Ilham Shakirov held a special place in this area. An originally melodious and strong voice, a deep understanding of his people's ethnic psychology and his ability to reveal it through song, high performing skills – these were the wonderful qualities that allowed Ilham to convey the full depth of the content and the beauty of the Tatar folk melody emotional forms. Ilham's work can be called a special period in the performance of Tatar folk melodies" [1, pp. 51–52]. Ravil Fakhrutdinov speaks positively about the performance of the ancient Tatar song "Kara urman" ("A Thick Forest") by Ilham Shakirov: "In recent years, Ilham Shakirov sang this song without any accompaniment, giving it a different tone and sound. The voice of Ilham, the melodious voice of a lonely young man riding through a thick and dark forest on horseback on a dark night, revealed the secret thoughts of the people". In particular, the writer

comes to a significant conclusion, emphasizing that the concept of "a thick forest" is neither a geographical, nor a geomorphological concept: "it is a philosophical, sociological concept. The thick forest is a symbol reflecting the gloomy life of the people in hard times" [1, p. 54]. Ravil Fahretdinov also gives an interesting and informative review of the song "Sin sazynny uinadyn" ("You Played the Saz") to the words of Naki Isanbet, that was in Ilham Shakirov's repertoire: "Ilham Shakirov rediscovered the aesthetic height, philosophical depth and passionate feeling of folk songs not only for music lovers, but also for professional musicians and composers. This means that he was not only a singer-performer, but also conducted socially significant scientific work" [1, p. 64]. This section tells that Ilham Shakirov was a folk singer who performed in different republics and regions of the Soviet Union and describes the significance of these performances: "the territory from the Baltic States in the west to Primorye in the east, from the Murmansk expanses in the north to Dushanbe in the south – this was the geography of popularity of Ilham's songs"; "Tatar boys and girls who had previously lived outside Tatarstan and had forgotten their native language, culture and art, after hearing Ilham's voice, began to think about their national culture, and not only that, they saw another beauty that they had never seen before"; "Prominent figures of culture and art of other nationalities, who heard Ilham sing for the first time, highly appreciated his voice, expressed admiration for the beauty of Tatar songs performed by him" [1, pp. 66–67]. At the same time, some people say that Ilham Shakirov breathed new life into Tatar songs: "In general, the role of Ilham in making this or that song widespread among the people was huge. This is manifested, on the one hand, by the fact that he had a wonderful voice; on the other, by his ability to get along well with composers and poets…" [1, p. 74]. The reason for the singer's popularity was connected, both with his lifestyle, with his spiritual characteristics ("Being surrounded by common people from his early age, sharing with them the joys and bitterness of life, having a subtle soul and feeling all the beauty of folk songs – these qualities helped Ilham become a famous master and singer" [1, p. 77]), and with his daily titanic work ("Ilham Shakirov, who had a great sense of responsibility, tirelessly selected his repertoire, created song programmes, setting an example for many singers" [1, p. 74]).

In the second section, the compiler includes two literary works in different genres dedicated to Ilham Shakirov: "Zhyrga salyp khat zhiberdem" ("Sending a Message by Enclosing It in a Song") by Magsum Latifullin, based on memoirs, excerpts from letters, familiarizing the readers with Ilham Shakirov's acquaintance with our famous writers and poets: Khasan Tufan, Fatikh Khusni, Afzal Shamov and composer Rustem Yahin, and the fictional work of the poetess and journalist Flera Nizamova "Ilhamlanu" ("Get Inspired") (2024). In both works, the feeling of longing is intertwined with wonderful memories of the singer. The work of Flera Nizamova introduces readers to Ilham Shakirov in everyday life, showing him as a simple earthly person: "Ilham abyi had simplicity, natural wisdom, a subtle sense of life and a deep mind. Apparently, nature itself knew in advance and selectively invested such qualities into the unborn child" [1, p. 116].

The director of the "Zhyen" Foundation, who perceived Ilham Shakirov as a "spiritual brother and spiritual support", "first heard him singing in Kyrgyzstan, from a gramophone plate", he introduced Ilham Shakirov to the older generation of Central Asian Tatar intellectuals, and taking his advice in the 1990s, he moved from Central Asia to Kazan, and since then he has made great efforts to promote the Tatar people and Tatar culture. This section introduces the traditions of Tatar culture and language related to the singer's name, written by Fuat Rafikov, who "is leading a great cause aimed at popularizing information about their outstanding personalities, their lives, deeds, and the revival of historical memory and returning it to the people" [1, 104 p.], and presents his entry "'The Zhyen' Foundation and Ilham Shakirov": 'If I were asked what a Tatar song was like, where were its ancient roots?', I would answer: 'Listen to Ilham Shakirov'. And if I were asked: 'Which melody will survive the centuries and go into the future with the people?' I would also answer: 'The melody of Ilham'. Ilham's songs, linking the past and the future, unite, inspire, and encourage the Tatar world" [1, p. 107].

The number of works, written by Ilham Shakirov himself and included in the new book, has also increased. Marcel Galeev carefully studied the bibliography of Ilham Shakirov and enriched it with previously unpublished articles by the singer ("Khalyk zhyrlary" (Folk Songs"), "Khalyknyn khel-khalete zhyrlarynda chagyla" ("The State of the People Is Reflected in the Songs"), interesting essays presenting his creative portrait ("Soklangych tawysh" ("The Amazing Voice"), "Teatr – anyn donyasy" ("Theatre Is His World"), "Suz ostasy" ("Master of Words"), "Artistlar"

("Artists"), "Izhadi etkem" ("My Creative Father"), "Chyn beznenche monly zhyr") ("Our Real Melodic Language..."), "Ul boek zhyrchy ide" ("He Was a Great Singer"), etc.), and his appearances on television and radio broadcasts.

The third section of the collection contains poems, articles, memoirs, prose articles by creative personalities (teachers, writers, singers, composers, journalists, etc.) related to Ilham Shakirov. After all, as Marcel Galeev writes, "if you look into the legacy of dedications, there is probably no Tatar poet, from the gray-haired Tatar wormwood Khasan Tufan, to young people whose names are just emerging in today's poetry, no writers, scientists, or art historians, who would not write an ode to him, would not utter a word coming from their hearts. It is the voice of the people that is the sea itself". [1, p. 4]. All the rich materials, collected here, contribute to the comprehensive disclosure of the singer-composer's personality. For example, the prose poems "Mon padishasy" ("The Padishah of Melodies") by Rabit Batulla, Razil Valeev's conversation with the famous singer "Inspiration / Ilham will live as long as the people live", "Khalyk koilere hem Ilham Shakirov" ("Folk Melodies and Ilham Shakirov") by Ravil Fahretdinov, "Khalyk monyn yaklap" ("In Defense of a Folk Melody") by Naki Isanbet, "Anyn uzenchelege…" ("His Characteristic Feature...") by Gumer Bashirov, "Khodai birgen" ("God Gave") by Amirkhan Eniki, "Tukay bashynnan syipar ide" ("Tukay Would Pat Him on the Head") by Sibgat Khakim, "Minnen bekhetle keshe yuktyr" ("There Is No Happier Person than Me") by Hamduna Timergalieva, "Legendar shekhes" ("The Legendary Personality") by Zile Sungatullina, "Tatar mony alpary" ("The Hero of the Tatar Melody") by Rkail Zaidulla and many other publications. Interesting and enlightening are the collection recordings by Tatar scientists who live abroad. They explain that the Tatars, forced to go abroad, are thirsty for the "healing wind of a Tatar melody" and weep as they listen to the recordings of Ilham Shakirov who became a legendary singer during his lifetime. It also shows that Ilham Shakirov with his melodious voice, being the most popular singer both at home and abroad, "touched the strings of their souls" and filled the hearts of the Tatars who settled in different regions of the Soviet Union in those years and the Tatars living abroad with longing. Who else among our singers had such a fate?... For example, the Tatar historian, Turkologist, Prof. Yulai Shamiloglu, who lived in America, shared the reminiscences of his youth in his memoirs "Ilham Shakirov and the Tatars of New York": "In 1975, I entered Columbia University and began visiting a Russian bookstore in the city centre, in Lower Manhattan. I was looking for books about the languages, history, and culture of the Turkic peoples there. One day, in the record department of the store, I came across a vinyl record with songs by Ilham Shakirov and presented it to my father. Listening to Ilham's songs was the greatest gift in the world for my father. During this period, Ilham Shakirov became the most popular singer among the Tatars of New York. My father always listened to Tatar songs on Sundays and remembered the relatives in our homeland. When my father listened to the songs of Ilham Shakirov, his eyes were filled with tears, and he wept" [1, p. 318]. The Tatar historian Nadir Davletov (1944–2021), who worked for many years as a professor at Marmara University in Istanbul, the capital of Turkey, also praised Ilham Shakirov in his congratulatory letter "Rekhmetler kunderep kalabyz" ("Showing Gratitude") on the occasion of the singer's 75th birthday: "In the 1970s, our relatives, living in Finland, began to talk about Tatar singers from Kazan, who came there with concerts from time to time. As soon as these singers heard the voice of Ilham Shakirov, recorded on magnetic tape, their hearts were affected by the healing wind of the Tatar melody, and these melodies began to flow, touching the strings of their souls. The first time I saw the great singer was in Tatarstan in August 1992 when a new spirit captured the Tatars. On August 11, the Kazan Kremlin officially hosted the Eid al-Adha Prayer (the festive prayer of Kurban-bayram) for the first time. When the prayer ended and the people began to disperse, we noticed that Ilham abyi was standing next to us. A lot of people gathered around him, and we also came up and greeted him and wished him a happy holiday. Meeting this legendary artist and his handshake made me happy like a child who received a festive gift" [1, p. 320]. In the 1990s, Ilham Shakirov came to Ankara, the capital of Turkey, where he met with representatives of the Tatar community and performed his songs. His name was heard by the Muhajir-Tatars living in Turkey during the time of the "Iron Curtain". His songs were loved by the listeners. The Tatars, living in Turkey, or Turks who have Tatar roots, even today listen with love to Ilham Shakirov's and other Tatar singers' songs. For example, in his interview, Lavant Bulut, a Turk by nationality but with Nogai Tatar roots and married to a Tatar woman, answered the question "What songs do you like?", and he said: "Ilham Shakirov, Alfiya Avzalova and Khaidar Bigichev". The interviewer, KFU student Adilya Zakirova, wrote: "I was impressed by these words, or rather, the fact that

Tatar music is familiar and, most importantly, is in demand among non-Tatar audiences” [6].

Unfortunately, Tatar music cannot become popular among Turks in Turkey, as Tatar songs differ significantly from Turkish music and Turkish songs. Turkish scientists, working in the field of art, have so far avoided the work of Ilham Shakirov. But we hope that the situation will change in the future, and we would like to believe that not only Tatars living in Turkey, but also Turks will recognize and love the great Tatar singers, especially Ilham Shakirov.

The third part of the collection contains poems, dedicated to Ilham Shakirov, by Khasan Tufan, Renat Kharis, Robert Akhmetzhan, Zulfat, Lena Zhagyirzhan, Zinnur Mansurov, Gazinur Murat, Kharras Ayup, Nuri Arslan, Nazhar Nazhmi, Ildar Yuzeev, Gamil Afzal, Radif Gatash, Robert Minnullin, Gulshat Zainasheva, Mudarris Aglyam, Flura Nizamova and many other poets and poetesses of the older and younger generations.

The fourth chapter of the collection consists of farewell speeches. It presents obituaries, official speeches by the Republic’s leaders, and the articles by representatives of creative intellectuals written to convey their condolences. All of them express deep sorrow over the death of Ilham Shakirov, the great son of the Tatar people.

The appendix to the book is also noteworthy. It presents the main dates of the life and creative work of Ilham Shakirov.

This collection contains very rich and valuable information about the life and creative path of the outstanding singer, interesting not only for novice readers, but also for those who knew this great personality well. Undoubtedly, this popular science collection will attract the attention of Ilham Shakirov’s, “Padishah of Melodies” (R. Batulla), fans all over the world and make their strings of souls tremble.

**References**

1. *Ilham Shakirov: fənni-populyar җyentyk* (2024) [Il'ham Shakirov: A Popular Science Collection]. Təz. M. B. Galiev 536 p. Kazan, Җyen. (In Tatar)

2. Fəkhretdinov, R. (1973). *Җyrchy: (Ilham Shakirov)* [The Singer: (Ilham Shakirov)]. 78 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

3. *Ilham* (1995) [Ilham]. Təz. R. Vəliev. 126 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

4. *“Ilahi Ilham”: Ilham Shakirovnyң tuuyna 85 el* (2020) [“Divine Ilham”: 85 Years since the Birth of Ilham Shakirov]. Təz. Gərəi Rəkhim. 184 p. Kazan, Җyen. (In Tatar)

5. Galiev, M. (2011). *Əsərlər. Alty tomda* [Works. In Six Volumes]. 2 t. 400 p. Kazan, “Idel-Press” nəshr., (In Tatar)

6. Bulut, L. (2021). *Ilham Shakirov, Əlfiya Avzalova, Khəidər Bigichev iәçatyn yaratam...* [Lavant Bulut: “I love the work of Ilham Shakirov, Alfiya Avzalova, Khaidar Bigichev...”]. Shəhri Kazan, 17 gyinvar, 2021. https://shahrikazan.ru/news/yazmalar/lvnt-bulut-ilam-shakirov-lfiya-avzalova-khydr-bigichev-iatyn-yaratam. (In Tatar)

# ҖЫР ДӘҮЛӘТЕНЕҢ ХАНЫ ТУРЫНДА ЯҢА КИТАП («ҖЫЕН» ФОНДЫ ЧЫГАРГАН «ИЛҺАМ ШАКИРОВ» ФӘННИ-ПОПУЛЯР ҖЫЕНТЫГЫНА БӘЯЛӘМӘ)

**Чулпан Әфраим кызы Зарипова-Четин,**
Кавказ университеты,
Төркия, 36000, Карс шәһәре,
chulpancetin@gmail.com.

**Гүлшаһ Йылмаз,**
Афьон Коджатепе Университеты,
Төркия, Афьонкарахисар 0300, Афьонкарахисар шәһәре,
gulsahyilmaz4048@gmail.com.

Мәкалә легендар татар җырчысы Илһам Шакиров турындагы фәнни-популяр җыентыкка рецензия булып тора. Китапта тәкъдим ителгән биографик, әдәби, фәнни-популяр материалларга бәя бирелә.

**Төп төшенчәләр:** татар мәдәнияте, татар музыкасы, Илһам Шакиров, җыр традицияләре, халык җыры

**Сылтама өчен:** Зарипова-Четин Ч.Ә., Йылмаз Г. Җыр дәүләтенең ханы турында яңа китап («Җыен» фонды чыгарган «Илһам Шакиров» фәнни-популяр җыентыгына бәяләмә) // // Tatarica. 2025. № 1 (24). 153–162 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-153-162

2024 елда «Җыен» фонды бөек җырчыбыз Илһам Гыйльметдин улы Шакировка багышланган «Илһам Шакиров» исемле фәнни-популяр җыентык чыгарды [1]. Бу китапка җырчының чордашлары – галимнәр, язучы-әдипләр, артистлар, җәмәгать эшлеклеләре тарафыннан олылап әйтелгән җылы сүзләр һәм кадерле фикерләр кергән. Әлеге җыентык, төзүче Марсель Галиев фикеренчә, «гасырга бер генә туа торган мәшһүр шәхескә мәдхия, сүзләрдән һәйкәл булып» [1] кабул ителә.

Татар халкының саекмас моң чишмәсе «кичәге, бүгенге, киләчәкле Илһам»ына [1, 3 б.] багышланган берничә китап моннан алда да дөнья күргән иде. Мәсәлән, 1973 елда Равил Фәхретдинов Илһам Шакиров турында «Җырчы» дигән китап язды [2]. Җырчы-композиторның 80 еллык юбилее уңаеннан Рәзил Вәлиев тарафыннан «Илһам» исемле китап-альбом төзелде [3]. Ә тагын биш ел узгач, Гәрәй Рәхим, «Җыен» фонды ярдәме белән, «Илаһи Илһам» исемле яңа китап-альбом әзерләде [4]. Биредә укучыларга җырчының тәрҗемәи хәле, җыр сәнгате хакында Илһам Шакиров үзе язган һәм аңа багышланган кызыклы, тирән мәгънәле мәкаләләр, йөрәк җылысы белән язылган якты истәлекләр, шулай ук күп санлы фоторәсемнәр тәкъдим ителде.

2024 елда исә, бөек җырчының тууына 90 ел тулу уңаеннан, «Җыен» фонды 4 бүлектән торган яңа җыентык нәшер итте [1]. «Илһамлы халыкның илханы булыр» исемле кереш сүзендә китапны төзүче Марсель Галиев үзенең хәтирәләре белән уртаклашып, Илһам Шакировның тәрҗемәи хәленә туктала, музыка сәнгатендә һәм татар тормышында алган әһәмиятле урынын билгели: «Татар җыр галәменә илленче еллар уртасында кинәт сызылып кергән йолдыз, Эстониянең Татарика күленнән алып Ерак Көнчыгышның Татар бугазына чаклы киңлекләргә таралган халкыма сихәт-дәва, яшәүгә өмет-юаныч биргән, кабатланмас аһәңнәре белән хәтер-рухны уята алган Илһам ул.» [1, б. 3]. Язучы «Татар моңындагы кодрәтле тылсымны» тыңлар өчен, укучыны «заман-чор күңелендә сирәк яңгыраш тапкан «Сәгать чылбыры», «Мәдинәкәй», «Кара урман», «Уел», «Тәфтиләү» кебек дистәләрчә җырларга канат куйган, тамашачыга сәгадәтле минутлар бүләк иткән, йөргән ил-җирләрдә өлкәннәр белән аралашып, бакый заманның онытылган көйләрен табып алып кайтып, аларга яңа гомер биреп, үзе әйтмешли, «халыктан алып, йөрәге аша үткәреп, яңадан халыкның үзенә кайтарган» бөек җырчы Илһам Шакировның тормыш һәм иҗат дөньясына сәяхәт итәргә чакыра һәм җырчыга Күкләр тарафыннан йөкләнгән миссияне хәтерләтеп, эндәшә: «Ходай тылсымыннан яратылган сәмави тавышың белән уят газиз җаннарны! Актарылсын хәтер! Сүнгән учак урыннарында кузлар кабынсын, дәвер утларына салып, чайкап ал кыйбласын җуйган җаннарны! Җырла Син, сулкылдасын бәгырь, тетрәнсен рух, җылатып юат мәртәбәле татар дөньясын! Син – кара урман Иясе, моң Иясе…» [1, б. 28]. Җыентыкка язган кереш сүзендә Марсель Галиев үзенең «Рух» китабыннан алынган «Галибанә моң» исемле лирик эссесын да керткән. Бу эсседа ул Илһам Шакиров иҗатының да алтын баганасы булган татар моңы турында фәлсәфи төшенчәләрен укучы белән уртаклашып, аңа татар халкының тарихта үткән шанлы юлын хәтерләтә: «Татар моңында – Алтын бүре башы чигелгән байракларын җилфердәтеп, карабаир юргаларда кыйтгаларны биләп тә, төрле ил-исемнәргә таркалган төрекләрнең Сак белән Сок язмышына тиң үкенечле хәсрәте бар! ...Татар моңында – Алтын Урданың җилгә изүен ачкан балбаллы далаларында Идегәйдән илсез калган мөсафир-кыпчаклар яккан учакларның әрнүле күмер пышылдаулары бар! ... Татар моңында – Идел карамаларыннан алып малахит Урал сыртлары аша Себер карагайларына кадәрге киңлектә дәрья булып шаулаган кара урманнарның гөнаһсыз-шомлы тирәнлеге бар!» [1, б. 29; б. 30]. Адлер Тимергалин бәяләмәсенә кушылып, без дә мондый күркәм әдәби портрет, аңа җан (рух) өрерлек язучыбыз әлегә чаклы булмаган һәм көнебездә дә мондый каләм остасы күренми дип әйтә алабыз: «Марсель Галиев бәхетле: ул тел остасы. Табигать аңа абсолют зәвык бүләк иткән, тел ачкычларын ул Ходайдан алган. Нәфислек үрнәкләрен мул чәчә Марсель Галиев» [5, б. 374; б. 383]. Гомумән, Марсель Галиевнең Илһам Шакиров турында язганнырын укыгач, шундый теләк туа күңелдә: «Эх, Марсель абый

оста һәм шагыйранә әдәби теле белән бөек җырчыбыз турында роман язса иде!» Чөнки аның кереш сүзе, бәлки якында язылачак роман сәхифәләренең нәкъ үзе...

Җыентыкның «Илһамны сагынып» дип аталган беренче бүлеккә Илһам Шакиров турында язылган бердәнбер әсәр – Равил Фәхретдиновның 1973 елда басылып чыккан «Җырчы» хезмәте кергән. Илһам Шакировның бик кадерле истәлекләренә һәм иҗатын яратып тыңлаучылардан алган хатлардан өзекләргә дә урын бирелгән бу хезмәт, җырчының тормыш һәм иҗат юлы белән бер рәттән, дәһшәтле сугыш һәм сугыштан соңгы еллардагы авыл тормышын күзаллау мөмкинлеге дә тудыра. Равил Фәхретдинов Илһам Шакировка, аның җыр сәнгатенә, күңелләрне тетрәтерлек тавышына, тирән моңына, югары башкару осталыгына ифрат зур бәя бирә. Язучы, «Илһамның, җырчы буларак, халык моңыннан нәрсәләр табуын, халыкка аның үз җәүһәрләрен нинди формада кабат кайтарып бирүен» дә ассызыклый: «Композиторларыбыз әсәрләренең халык арасында дан казануы бу әсәрләрнең халык музыкасы, халык моңнары рухында язылган булуыннан килә. Халык җырларында халык иҗатының, халык даһилыгының ачылып бетмәгән хәзинәләре ята. Бу өлкәдә Илһам Шакиров аерым бер урын алып тора. Үзенә генә хас моңлы һәм көчле тавыш, халыкның этник психологиясен бөтен йөрәге белән аңлау һәм аны җыр аша ачып бирә белү, югары башкару осталыгы – менә бу гүзәл сыйфатлар Илһамга татар халык көйләре эчтәлегенең бөтен тирәнлеген һәм эмоциональ формаларының матурлыгын җиткерә алырга мөмкинлек бирәләр. Илһам иҗатын татар халык көйләрен башкаруда аерым бер чор дип карарга була» [1, б. 51-52]. Равил Фәхретдинов Илһам Шакировның борынгы татар җыры «Кара урман»ны башкаруы турында да саллы фикерләр әйтә: «Илһам Шакиров соңгы елларда бу җырны бернинди аккомпанементсыз, ялгызы гына җырлап, аңа икенче бер төсмер һәм яңгыраш бирде. Илһам тавышы, караңгы төндә калын һәм кара урман аша атка утырып барган ялгыз егетнең моңлы авазына кушылып, халык әйтергә теләгән уйларны ачып бирә». Аеруча, язучы «Кара урман» көендәге кара урман төшенчәсенең дә географик, геоморфологик төшенчә генә булмаганын ассызыклап, әһәмиятле нәтиҗәгә килә: «Ул – философик, социологик төшенчә. Кара урман – халыкның авыр көннәрендәге шомлы, караңгы тормышын чагылдыру символы ул.» [1, б. 54]. Илһам Шакиров репертуарына кергән Нәкый Исәнбәт сүзләренә язылган «Син сазыңны уйнадың» җыры турында да Равил Фәхретдинов кызыклы һәм мәгънәле фикерләр әйтә: «Илһам Шакиров халык җырларының эстетик югарылыгын, фәлсәфи тирәнлеген һәм кайнар хисен музыка-җыр яратучылар өчен генә түгел, профессиональ музыкантлар һәм композиторлар өчен дә яңабаштан ачты. Димәк, ул җырчы-башкаручы булып кына калмады, иҗтимагый әһәмиятле гыйльми эш тә эшләде дигән сүз» [1, б. 64]. Бу бүлектә Илһам Шакировның халык җырчысы булуы, Советлар Берлегенең төрле республика һәм төбәкләрендә чыгыш ясавы һәм бу чыгышларның әһәмияте турында да языла: «Көнбатышта Балтыйк буеннан көнчыгышта Приморьега кадәр, төньякта Мурманск киңлекләреннән көньякта Дүшәнбегә кадәрге территория – менә Илһам җырларының популярлык географиясе»; «Моңа кадәр Татарстаннан читтә яшәп, үз ана телен, культурасын, сәнгатен оныта башлаган татар егетләре һәм кызлары, Илһам тавышын ишетеп, үз милли культуралары турында уйлана башлыйлар, ул гына да түгел, алар моңарчы күрергә туры килмәгән икенче бер матурлыкны күрәләр»; «Илһамның җырлавын беренче тапкыр ишеткән башка милләт культурасы һәм сәнгатенең күренекле эшлеклеләре аның тавышына югары бәя бирәләр, ул башкарган татар җырларының матурлыгына соклануларын белдерәләр» [1, б. 66-67]. Шул ук вакытта Илһам Шакировның татар җырларына яңа сулыш өрүе турында да уйланулар бар: «Гомумән, теге яки бу җырның халыкта киң таралыш алуында Илһамның роле зур. Бу, бер яктан, аның гүзәл тавышка ия булуында күренсә, икенчедән, аның композиторлар һәм шагыйрьләр белән гаҗәп матур итеп дуслаша белү сәләтенә бәйле» [1, б. 74]. Җырчының бу кадәр популяр булуының сәбәбе исә, бер яктан, аның яшәү рәвешенә, рухи үзенчәлекләренә бәйле («кече яшьтән халык арасында кайнау, аның белән бергә тормышның ачысын-төчесен һәм шатлыгын тату, халык җырларының бөтен гүзәллеген тоеп үсү, балачактан ук нечкә күңелле булып, матурлыкны аңлый белү – менә бу сыйфатлар Илһамның оста, мәшһүр җырчы булуына ярдәм иткәннәр» [1, б. 77]), икенче яктан, бу уңышның нигезендә көндәлек титаник хезмәт ятуы белән («Илһам Шакировның гаять зур җаваплылык хисе белән, армый-талмый репертуар, җыр программасы

төзүе – байтак җырчыларга үрнәк» аңлатыла [1, б. 74]).

Икенче бүлеккә шулай ук төзүче Илһам Шакировка багышланган төрле жанрдагы ике әдәби әсәр дә керткән: Мәгъсүм Латыйфуллинның истәлекләргә, хатлардан өзекләргә нигезләнгән һәм Илһам Шакировның Хәсән Туфан, Фатих Хөсни, Афзал Шамов кебек халкыбызның күренекле әдип һәм шагыйрләре, Рөстәм Яхин кебек мәшһүр композиторы белән танышып, иҗат юлына басуын аңлаткан «Җырга салып хат җибәрәм» исемле бәяны һәм шагыйрә, журналист Флёра Низамованың «Илһамлану» (2024) исемле беллетристик әсәре. Икесендә дә сагыну хисе җырчы турында матур хатирәләр белән үрелеп бара. Флёра Низамованың әсәре укучыларга Илһам Шакировны көндәлек тормышта, гади җир кешесе буларак та таныта: «Илһам абыйда шушындый гадилек тә, табигый аң-зиһен дә, тормышны нечкә тоемлау да, тирән акыл да – барысы бергә тупланган иде. Күрәсең, табигать үзе алдан ук белеп, туачак бер баласының орлыгына шундый сыйфатларны аерып, сайлап-иләп салгандыр инде» [1, б. 116].

«Җыен» фонды директоры, Илһам Шакировны «җандаш абый һәм рухи таяныч» буларак кабул иткән, «аның җырлавын беренче мәртәбә Кыргызстанда, патефон тәлинкәсеннән тыңлаган», Илһам Шакировны Урта Азиядәге өлкән буын татар зыялылары белән таныштырган, 1990 елларда аның сүзен тыңлап Урта Азиядән Казанга күчеп кайткан һәм бу еллардан башлап татар халкын, татар мәдәниятен таныту эшенә зур көч куйган, «халкыбызга үзенең күренекле шәхесләре, аларның тормышы, эш-гамәлләре хакындагы мәгълүматны популяр формада кайтаруга, тарихи хәтерне яңартуга юнәлтелгән зур бер хәрәкәтнең» [1, б. 104] башында торган Фуат Рәфыйковның «Җыен» фонды һәм Илһам Шакиров» дигән язмасы исә татар мәдәниятен һәм телен үстерү фондының җырчы исеме белән бәйле традицияләре белән таныштыра: «Татар җыры нинди җыр ул, аның борынгы тамырлары кайда?» – дип сорасалар, мин: «Илһам Шакировны тыңлагыз», – дип җавап бирер идем. Ә инде: «Гасырларны нинди моң кичеп үтәр, халык белән бергә киләчәккә барыр?» – дигәннәргә шулай ук «Илһам моңы», – дияр идем. Үткән белән киләчәкне бәйләп, Илһам җыры-моңы татар дөньясын берләштерә, илһамландыра, канатландыра…» [1, б. 107].

Яңа китапка кертелгән Илһам Шакиров үзе язган әсәрләрнең саны да арткан. Марсель Галиев бөртекләп, игътибар белән Илһам Шакировның библиографиясен барлап чыккан һәм аны җырчының моңарчы кертелмәгән мәкаләләре («Халык җырлары», «Халыкның хәл-халәте җырларында чагыла»), иҗади портрет тудырган кызыклы очерклары («Соклангыч тавыш», «Театр – аның дөньясы», «Сүз остасы», «Артистлар», «Иҗади эткәм», «Чын безнеңчә моңлы тел... », «Ул бөек җырчы иде» һ.б.), телерадиотапшыруларда булган чыгышлары белән баеткан.

Җыентыкның өченче бүлегендә иҗади шәхесләрнең (укытучылар, язучылар, җырчылар, композиторлар, журналистлар һ.б.) Илһам Шакиров белән бәйле шигырьләре, мәкаләләре, истәлекләре, нәсерләре һәм әңгәмәләре урын алган, чөнки, Марсель Галиев язуынча, «Багышлаулар мирасына күз салсаң, татарның чал әреме – Хәсән Туфаннан башлап бүген исеме туып кына килә торган яшь каләм ияләренә кадәр Аңа мәдхия язмаган шагыйрь, йөрәктән чыккан сүзен әйтмәгән әдип, галим-голәмә, сәнгать белгече юктыр, мөгаен. Ә инде халык авазы – үзе бер дәрья» [1, б. 4]. Бирегә җыелган бай материалларның барысы да җырчы-композитор шәхесен төрле яктан ачарга ярдәм итә. Мәсәлән, Рабит Батулланың «Моң падишасы» нәсере, Разил Вәлиевнең мәшһүр җырчы белән «Халык яшәгәндә, илһам яшәр» әңгәмәсе, Равил Фәхретдиновның «Халык көйләре һәм Илһам Шакиров», Нәкый Исәнбәтнең «Халык моңын яклап», Гомәр Бәшировның «Аның үзенчәлеге…», Әмирхан Еникинең «Ходай биргән», Сибгат Хәкимнең «Тукай башыннан сыйпар иде», Хәмдүнә Тимергалиеваның «Миннән бәхетле кеше юктыр», Зилә Сөнгатуллинаның «Легендар шәхес», Ркаил Зәйдулланың «Татар моңы алпары» һәм башка күп кенә язмалар. Шулай ук җыентыкка урнаштырылган чит илләрдә яшәүче татар галимнәренең каләменнән төшкән язмалар да кызыклы һәм гыйбрәтле. Аларда чит илләрдә яшәп калырга мәҗбүр булган татарларның «татар моңының шифалы җиле»нә сусаулары һәм яшәгәндә үк легендага әверелгән җырчы Илһам Шакировның пластинкаларын елый-елый тыңлаулары аңлатыла. Ә бу инде Илһам Шакировның, чит илләрдә дә иң популяр җырчы булып, моңлы тавышы белән ул елларда Советлар Берлегенең төрле төбәкләренә чәчелеп яшәгән татарларга гына түгел, чит илләрдә яшәп калган татарларга да

туган илләрен хәтерләтеп, «күңел кылларын дулкынландырып», сагыш тулы йөрәкләрен парә-парә телгәләвен күрсәтә. Тагын кайсы җырчыбызга насыйп булды икән мондый язмыш?.. Мәсәлән, татарның Америкада яшәгән тарихчы галиме, тюрколог, профессор Юлай Шамилоглы «Илһам Шакиров һәм Нью-Йорк татарлары» дигән истәлек-язмасында яшьлек хәтирәләре белән уртаклаша: «1975 елда мин Колумбия университетына укырга кердем һәм шәһәр үзәгенә, Түбән Манхэттендагы рус китап кибетенә йөри башладым. Мин анда төрки халыклар телләре, тарихлары, мәдәниятләре турында китаплар эзли идем. Кибетнең пластинкалар бүлегендә бермәлне мин Илһам Шакиров җырлары язылган пластинкага юлыктым һәм аны әтиемә алып кайтып бүләк иттем. Илһам җырларын тыңлау әтием өчен дөньядагы иң зур бүләк иде. Шул чорда Илһам Шакиров Нью-Йорк татарлары арасында иң популяр җырчы булып китте. Әтием якшәмбе көннәрендә һәрчак татар җырлары тыңлый һәм илдә калган туганнарын искә төшерә иде. Илһам Шакиров җырларын тыңлаганда, әтиемнең ике күзе яшь белән тула һәм ул шыпырт кына елый иде» [1, б. 318]. Шулай ук татар тарихчы галиме, бик озак еллар Төркиянең башкаласы Истанбулда Мәрмәрә университетында профессор булып эшләгән Надир Дәүләт (1944–2021) тә Илһам Шакировка 75 яшь тулу уңаеннан язылган «Рәхмәтләр күндереп калабыз» исемле тәбрик хатында җырчыга югары бәя бирә: «1970 елларда Финляндиядә яшәүче туганнарыбыздан анда-санда Казаннан кайбер татар җырчыларының килеп концертлар бирүен ишетә башладык. Менә шушы җырчылар арасында Илһам Шакировның магнитлы тасмага язылган әсәрләре яңгырый башлау белән, безнең күңелләребезгә татар моңының шифалы җиле кагылды, күңел кылларыбызны дулкынландыручы көйләр агылды. Ә минем бөек җырчыны беренче мәртәбә күрүем Татарстанда татарларга яңа рух килгән 1992 елның августында булды. Менә 11 август көнне Казан Кремлендә беренче мәртәбә рәсми рәвештә Корбан гаетенең бәйрәм намазы бара. Намаз бетеп, халык таралганда карасак – Илһам абый янәшәбездә басып тора. Тирәсендә күпләп кеше җыелган, без дә килеп исәнләштек, бәйрәм белән котлаштык. Безнең өчен легенда булган бу атаклы сәнгатькәр белән танышу, аның кулын кысу мине бәйрәм бүләге алган балалар сыман шатландырды» [1, б. 320]. 1990 елларда Илһам Шакиров Төркиянең башкаласы Әнкарага килеп, биредә татар җәмгыяте белән очрашып, чыгыш ясый. Аның исемен Төркиядә яшәүче мөһаҗир татарлар әле «тимер пәрдә» заманында ук ишетә. Җырларын да яратып тыңлаучылар була. Төркиядә яшәүче татарлар яисә тамырларында татар каны булган төрекләр бүген дә Илһамм Шакировны һәм күп кенә башка татар җырчыларның иҗатын яратып тыңлый. Мәсәлән, үзе төрек булса да тамырлары ногай татарларына барып тоташкан һәм татар кызына өйләнгән Ләвәнт Болыт бер интервьюсында «Үзегез нинди җырлар яратасыз соң?» дигән сорауга «Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Хәйдәр Бигичев иҗатын” дип җавап бирә. Интервьюны алган КФУ студенты Әдилә Закирова «мине бу сүзләр, дөресрәге, татар моңының татар булмаган аудитория арасында таныш, ә иң мөһиме – кирәк булуы сокландырды һәм шатландырды», – дип яза [6].

Кызганыч, татар музыкасы, татар җыры төрек музыкасыннан, төрек җырыннан шактый нык аерылып торганга күрә, Төркиядә төрекләр арасында популяр булып китә алмый. Сәнгать өлкәсендә эшләүче төрек галимнәре дә бүгенгә кадәр Илһам Шакировның иҗатын читләп үтте. Ләкин киләчәктә бу вәзгыять үзгәрер һәм Төркиядә яшәүче татарлар гына түгел, төрекләр дә татарларның бөек җырчыларын, бигрәк тә Илһам Шакировны таныр һәм яратып тыңлар дип ышанасы килә.

Җыентыкның өченче бүлегендә Хәсән Туфан, Ренат Харис, Роберт Әхмәтҗан, Зөлфәт, Лена Шагыйрьҗан, Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Харрас Әюп, Нури Арслан, Нажар Нәҗми, Илдар Юзеев, Гамил Афзал, Рәдиф Гаташ, Роберт Миңнуллин, Гөлшат Зәйнашева, Мөдәррис Әгъләм, Флюра Низамова һ.б. күп кенә өлкән һәм яшь буын шагыйрь һәм шагыйрәләрнең Илһам Шакировка багышланган күркәм шигырьләре урын алган.

Җыентыкның дүртенче бүлеге исә хушлашу сүзләреннән тора. Монда некрологлар, Республика җитәкчеләренең рәсми сүзләре һәм иҗади интеллигенция вәкилләренең кайгы уртаклашу максаты белән язылган мәкаләләре бирелгән. Аларның барысында да татар халкының бөек улы Илһам Шакировның якты дөньядан китүенә карата тирән кайгы ачык сизелә.

Китапның кушымтасы да игътибарга лаек. Анда Илһам Шакировның тормыш юлына һәм

иҗат эшчәнлегенә караган төп даталар бирелгән.

Күренекле җырчының тормыш һәм иҗат юлы белән беренче мәртәбә танышучылар өчен генә түгел, бу бөек шәхесне яхшы белгән кешеләр өчен дә бу җыентыкка ифрат бай һәм кыйммәтле мәгълүмат җыелган. Һичшиксез, әлеге фәнни-популяр җыентык – «моң падишасы» (Р. Батулла) Илһам Шакировның бөтен дөньяга сибелеп яшәүче җанатарларының игътибарын җәлеп итәчәк һәм аларның күңел кылларын тибрәтәчәк, дип ышанып калабыз.

**Әдәбият**


1. Илһам Шакиров: фәнни-популяр җыентык / Төз. Галиев М. Б. Казан: Җыен, 2024. 536 б.
2. *Фәхретдинов Р.* Җырчы: (Илһам Шакиров). Казан: Татар. кит. нәшр.,1973. 78 б.
3. Илһам / төз. Р. Вәлиев. Казан: Татар. кит. нәшр, 1995. 126 б.
4. «Илаһи Илһам»: Илһам Шакировның тууына 85 ел / төз. Гәрәй Рәхим. Казан: Җыен, 2020. 184 б.
5. *Галиев М.* Әсәрләр. Алты томда. 2 т. Казан: «Идел-Пресс» нәшр., 2011. 400 б.
6. *Булут Л.* Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Хәйдәр Бигичев иҗатын яратам... // Шәһри Казан, 17 гыйнвар, 2021. https://shahrikazan.ru/news/yazmalar/lvnt-bulut-ilam-shakirov-lfiya-avzalova-khydr-bigichev-iatyn-yaratam


# НОВАЯ КНИГА О ЛЕГЕНДАРНОМ ТАТАРСКОМ ПЕВЦЕ (РЕЦЕНЗИЯ НА НАУЧНО-ПОПУЛЯРНЫЙ СБОРНИК «ИЛҺАМ ШАКИРОВ», ВЫПУЩЕННЫЙ ФОНДОМ «ҖЫЕН»)


**Чулпан Афраимовна Зарипова-Четин,**
Кавказский университет,
Турция, 36000, город Карс,
chulpancetin@gmail.com.

**Гюлшах Йылмаз,**
Университет Афьон Коджатепе,
Turkey, 0300, Afyonkarahisar/Center,
gulsahyilmaz4048@gmail.com.



В рецензии на научно-популярный сборник о легендарном татарском певце Ильгаме Шакирове дается оценка представленным в книге биографическим, литературным, научно-популярным материалам.



**Ключевые слова:** татарская культура, татарская музыка, Ильгам Шакиров, песенные традиции, народная песня

**Для цитирования**: Зарипова-Четин Ч.А., Йылмаз Г. Новая книга о легендарном татарском певце (рецензия на научно-популярный сборник «Ильгам Шакиров», выпущенный фондом «Җыен») // Tatarica. 2025. № 1 (24). pp. 153–162. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-153-162